# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУЕМБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТУЕМБАШ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

## КАРАР

21 ноябрь, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

«- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү өчен кулланыла торган сулыкларны), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Гарипов